СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**«25» октябрь 2021 ел** **№5**

**Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Кышкар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Яңа Кишет авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Кышкар авылында Кышкар авылы, Новая урамы, 125 нче йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 19 ноябренә 14 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Кышкар авылында Кышкар авылы, Новая урамы, 125 нче йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 19 ноябренә 15 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1 нче этап: Мира, Новая урамнарында яшәүчеләр;

2 нче этап: Мостовая, Победа урамнарында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Кышкар авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;

- Кышкар авылында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру, 1 данә.

- Кышкар авылында Мостовая урамы 45 нче йорттан 55 нче йортка, асфальт-бетон катламлы юлдан 53 нче йортка кадәр юл-урам челтәре нигезен вак таш-грунттан каплау;

- Кышкар авылында Мира, Мостовая, Победа урамнарының урам-юл челтәренә вак таш җәеп, автомобиль юлларын тигезләү;

- Кышкар авылы зиратының бер өлешен коймалап алу өчен материаллар сатып алу;

- янгын гидрантларына комплект җиһазлары сатып алу (1 данә янгын җиңсәсе, көчеш башламы, янгын колонкасы, янгын стволы).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

5. Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Кышкар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Яңа Кишет авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урында мәгълүмат стендында ТР, Арча районы, Кышкар авылы, Новая урамы, 125 нче йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Э.Ф.Минзянова